Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
«Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР

№ 3                                   08 май 2020 ел

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәге сораулар буенча гавами тыңлаулар билгеләргә:
- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Тихоновка ав., Терешкова ур. адресы буенча 1771 кв.м. мәйданы булган төзелә торган җир кишәрлегенә карата «Спорт»-5.1 коды- җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән «Спорт мәйданчыгы» төренә рөхсәт бирү.
-«Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге, «Түбән Мактама ш.т.б.» муниципаль берәмлеге, Әлмәт муниципаль районы Яңа Нәдер авыл җирлеге территорияләре буйлап узучы «Төен – Исмәгыйль Реконструкция ВЛ 110 кВ» объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча фикер алышу.
2. Билгеләргә:
2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты – 2020 елның 5 июне 9: 00 сәгатьтә.
2.2. Беренче сорау буенча гавами тыңлаулар уздыру срогы - бер айдан да артык түгел, икенче сорау буенча - әлеге карар басылып чыккан көннән алып бер айдан да ким һәм өч айдан да артык булмаган вакытка.
2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама ш.т.б., Некрасов ур., 18 А й.
2.4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Түбән Мактама ш.т.б., Некрасов ур., 18 А й. адресы буенча урнашкан Түбән Мактама поселок башкарма комитетына гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гаризалар бирергә
2.5. Гавами тыңлауларында катнашу өчен гаризалар бирү вакыты-2020 елның 05 июненә кадәр.
3. Түбән Мактама бистә башкарма комитетына (Нафикова Г.Р.) гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.
4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Мактама бистә башкарма комитеты җитәкчесе Г.Р. Нафиковага йөкләргә.

Түбән Мактама ш.т.б. башлыгы:                    В.Н. Михайлов